Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Данауровка авыл җирлеге Советы
Карары

2019 елның 24 сентябре 75/1

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
“Данауровка авыл җирлеге”
муниципаль берәмлеге
милкендәге муниципаль мөлкәтне
хосусыйлаштыру
Тәртибен раслау турында

Чистай шәһәре прокурорының 2019 елның 5 маендагы 02-08-03-2019 номерлы күрсәтмәсен карап тикшергәннән соң, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законына таянып, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Данауровка авыл җирлеге” Уставы белән, муниципаль милекне нәтиҗәле сату максатыннан, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Данауровка авыл җирлеге Советы

Карар бирә:

1. Татарстан Республикасының Чистай муниципаль районы “Данауровка авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге милкендәге муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру тәртибе турындагы Нигезләмәне әлеге карарның кушымтасы нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә игълан итәргә һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (www.chistopol.tatarstan.ru).
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Данауровка авыл җирлеге Советының законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Данауровка авыл җирлеге
башлыгы В.К. Садретдинова

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Данауровка авыл җирлеге Советының
2019 елның
24 сентябрендәге 75/1 номерлы
карарына
Кушымта

**1.Гомуми нигезләмәләр**

1.Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Данауровка авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге милкендәге муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру тәртибе турындагы Нигезләмә түбәндәге чыганаклар таянып эшләнде:

- Россия Федерациясе Граждан кодексы;

- “Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында”гы 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон;

- “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон;

- “Россия Федерациясендә бәяләү эшчәнлеге турында”гы 1998 елның 29 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль закон;

- “Дәүләт һәм муниципаль милекне электрон формада сатуны оештыру һәм үткәрү турында” 27 август, 2012 ел, №860 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары;

- Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Данауровка авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы;

- муниципаль милекне хосусыйлаштыру мәсьәләләрен җайга салучы башка норматив хокукый актлар.

1.2. Муниципаль милекне хосусыйлаштыру дигәндә, Татарстан Республикасының Чистай муниципаль районы “Данауровка авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге милкендә (алга таба текст буенча – Җирлек) булган мөлкәтне физик һәм (яки) юридик затлар милкенә алу күздә тотыла.

1.3. Әлеге Нигезләмә муниципаль милекне хосусыйлаштырганда барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне һәм муниципаль милек белән идарә итү мөнәсәбәтләрен җайга сала.

1.4. Әлеге Нигезләмәнең гамәлдә булуы тартып алганда (отчуждение) барлыкка килә торган мөнәсәбәтләргә кагылмый:

1) җир кишәрлекләре, күчемсез милек объектлары урнашкан җир кишәрлекләрен, шул исәптән мөлкәт комплекслары урнашкан җир кишәрлекләрен сатудан тыш;

2) табигать ресурслары;

3) муниципаль торак фонды;

4) Россия Федерациясенең халыкара килешүләрендә каралган, муниципаль милек очраклары;

5) муниципаль милектә булган башка дини мөлкәтне, дини биналар һәм корылмалардан тиешле максатларда файдалану өчен, шулай ук инвалидларның һәм оешмаларның бердәнбер гамәлгә куючылары булып муниципаль милектә булган биналар, төзелмәләр һәм корылмалар түләүсез рәвештә дини оешмалар милкенә тапшырыла;

7) муниципаль унитар предприятиеләрне һәм муниципаль милекне үзгәртеп корганда төзелгән коммерцияле булмаган оешмалар милкенә тапшырыла торган коммерцияле булмаган оешмаларга Җирлек мөлкәт кертеме буларак тапшырыла торган муниципаль милекне үзгәртеп корганда барлыкка килгән коммерциячел булмаган оешмалар милкенә тапшыру;

8) хуҗалык алып бару, яки оператив идарә итү хокукында беркетелгән мөлкәтне муниципаль унитар предприятиеләр, муниципаль учреждениеләрдәге мөлкәтне муниципаль милеккә тапшыру;

9) суд карары нигезендә муниципаль милек;

10) Федераль законнарда каралган очракларда Җирлектә акцияләр бирүне таләп итү хокукы;

11) “Акционерлык җәмгыятьләре турындагы”гы 26.12.1995 ел, № 208-ФЗ Федераль законның 84.2, 84.7 һәм 84.8 статьяларында билгеләнгән тәртиптә, акционерлык җәмгыятьләре акцияләрен, шулай ук акционерлык җәмгыятьләре акцияләренә конвертацияләнгән кыйммәтле кәгазьләр сатып алган очракта;

12) “Россия Федерациясендә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре

турында”гы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә, Җирлек милек кертеме сыйфатында идарәче компания милкенә тапшырыла торган мөлкәт;

Әлеге пунктта күрсәтелгән муниципаль мөлкәтне тартып алу(отчуждение) башка федераль законнар һәм (яисә) башка норматив хокукый актлар белән җайга салына.

1.5. Федераль законнар белән әйләнеше рөхсәт ителми торган граждан хокуклары объектларына (әйләнештән алынган объектларга), шулай ук федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә бары тик дәүләт яки муниципаль милектә булырга мөмкин булган мөлкәтне (әйләнештән алынган объектларга) хосусыйлаштырырга мөмкин түгел.

1.6. Муниципаль милекне сатып алучылар физик һәм юридик затлар булырга мөмкин, моннан тыш:

- дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләре, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр;

- “Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында”гы 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясында каралган очраклардан тыш, устав капиталында Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары һәм муниципаль берәмлекләр өлеше 25 проценттан артып киткән юридик затлар өчен;

- теркәлү урыны булып Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган Салым салуның ташламалы салым режимын бирүче һәм финанс операцияләре (офшор зоналары) вакытында мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмаган, һәм алар үзләренең табышлы сатып алучылары, бенефициар хуҗалары һәм контрольлек итүче затлар турында Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә мәгълүмат ачуны һәм тапшыруны гамәлгә ашырмый торган юридик затлар; “Контрольлек итүче зат” төшенчәсе 2008 елның 29 апрелендәге 57-ФЗ номерлы “Ил оборонасын һәм дәүләт иминлеген тәэмин итү өчен стратегик әһәмияткә ия булган хуҗалык җәмгыятьләренә чит ил инвестицияләрен гамәлгә ашыру тәртибе турында”гы Федераль законның 5 нче маддәсендә дә кулланыла. “Отышлы сатып алучы” һәм “бенефициар хуҗа” төшенчәләре “Җинаятьчел юл белән алынган керемнәрне легальләштерүгә (юдыртуга) каршы тору һәм терроризмны финанслауга каршы тору турында”гы 2001 елның 7 августындагы 115-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясында күрсәтелгән мәгънәләрдә кулланыла.

Әлеге пунктта билгеләнгән чикләүләр үз теләкләре белән төзелмәгән һәм муниципаль милеккә караган җир кишәрлекләрендә урнашкан күчемсез милек объектлары милекчеләренә әлеге җир участокларын сатып алганда кагылмый.

1.7. Конституция төзелеше, әхлак, сәламәтлек, башка затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау, дәүләтнең оборона сәләтен һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында физик һәм юридик затларның аерым категорияләренең граждан мөнәсәбәтләрендә катнашуны федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләр муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру вакытында мәҗбүри.

“Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында”гы 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, хосусыйлаштырыла торган устав капиталларында үз өлешләрен, акцияләрен, җаваплылыклары чикләнгән җәмгыятьләр сатып ала алмыйлар.

1.8. Әлеге Нигезләмә белән җайга салынмаган муниципаль милекне тартып алу(отчуждение) мәсьәләләре Россия Федерациясе Граждан кодексы һәм “Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында”гы 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә җайга салына.

1.9. Кече һәм урта эшкуарлык субъектларының арендалана торган муниципаль күчемсез милекне хосусыйлаштыруда катнашу үзенчәлекләре федераль закон белән билгеләнергә мөмкин.

1.10. Нотариусларның һәм нотариаль палаталарның муниципаль милектә булган һәм аукционда, яки конкурста сату турында Карар кабул ителгән мөлкәтне хосусыйлаштыруда катнашу үзенчәлекләре Россия Федерациясенең 1993 елның 11 февралендәге 4462-1 номерлы нотариаты турында закон нигезләрендә билгеләнергә мөмкин.

## 2. Муниципаль милекне хосусыйлаштыруның төп максатлары һәм принциплары

2.1. Муниципаль милекне хосусыйлаштыруның төп максатлары булып түбәндәгеләр тора:

- муниципаль милек белән нәтиҗәле идарә итү нигезендә Җирлек бюджеты керемнәрен арттыру;

- икътисадый үсешне тәэмин итү, Җир һәм башка күчемсез милек базарын үстерү,

предприятиеләрнең рентабельле һәм тотрыклы эшчәнлеген тәэмин итү максатларында милек структурасын оптимальләштерү;

- муниципаль милек объектларының максималь санын гражданнар әйләнешенә кертү;
- хосусыйлаштыру объектларына инвестицияләр җәлеп итү.

Муниципаль милекне хосусыйлаштыру - яңартыла торган түләү чыганакларын булдыру һәм булган мөлкәтне нәтиҗәлерәк файдалану юлы белән Җирлек бюджетына өстәмә керемнәр алу бурычларын хәл итүне тәэмин итә;

- рентабельсез предприятиеләргә ярдәм итүгә бюджет чыгымнарын киметү;
- тузган торакны бетерү программасы буенча күчерелгән һәм архитектура, тарих һәм мәдәният һәйкәлләре булган күчемсез милек объектларын инвесторлар һәм яңа милекчеләр акчаларын җәлеп итү хисабына үзгәртеп кору.

2.2. Муниципаль милекне хосусыйлаштыру - муниципаль милекне сатып алучыларның тигезлеген һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең ачыклыгын тануга нигезләнә.

2.3. Муниципаль милек физик һәм юридик затлар милкенә бары тик түләүле нигездә генә бирелә (түләү, яки устав капиталына муниципаль мөлкәт кертелә торган акционер җәмгыятьләре акцияләрен муниципаль милеккә тапшыру юлы белән, яисә муниципаль унитар предприятиеләрне үзгәртеп кору юлы белән төзелгән Хуҗалык җәмгыятьләренең устав капиталында өлешләр кертү юлы белән барлыкка килгән акционер җәмгыятьләре акцияләрен муниципаль милеккә тапшыру юлы белән генә бирелә).

2.4. Муниципаль милекне хосусыйлаштыру җирле үзидарә органнары тарафыннан компетенция нигезендә “Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында”гы 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законда каралган тәртиптә мөстәкыйль рәвештә гамәлгә ашырыла.

2.5. Бәяләү эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары таянып, хосусыйлаштырыла торган муниципаль мөлкәтнең башлангыч бәясе муниципаль милекне бәяләү турындагы хисап нигезендә билгеләнә, бәяләү объектын бәяләү турында хисап төзелгән көннән алып “Интернет” челтәрендәге рәсми сайтта муниципаль милекне сату турында мәгълүмати хәбәр урнаштырылган көнгә кадәр алты айдан да артык вакыт узмаган шарт үтәлгән очракта.

## 3. Муниципаль милекне хосусыйлаштыру өлкәсендә җирле үзидарәнең вәкиллекле һәм башкарма органнары компетенциясе

3.1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Данауровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты (алга таба текст буенча – Җирлек башкарма комитеты) Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Данауровка авыл җирлеге Советы карары белән билгеләнгән очракларда (алга таба текст буенча - Җирлек советы) муниципаль милекне хосусыйлаштыру турындагы тәкъдимнәр әзерли һәм Җирлек Советының килешүенә (раславына) кертә.

3.2. Җирлек Советы федераль законнар нигезендә муниципаль милекне хосусыйлаштыру тәртибен һәм шартларын билгели; Җирлек Советы килештереп, яки расланганнан соң, читләштерелә торган муниципаль милек төрләре исемлеген билгели.

## 4. Муниципаль милекне хосусыйлаштыруны планлаштыру. Фараз планы.

4.1. Авыл җирлеге башкарма комитеты муниципаль милекне хосусыйлаштыруның Фараз планын (программасын) ел саен әзерли һәм раслау өчен җирлек Советына юллый.

4.2. Прогноз планында (Программа) муниципаль унитар предприятиеләр, шулай ук муниципаль милектә булган акционерлык җәмгыятьләре акцияләре, җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләрнең устав капиталындагы өлешләр, тиешле елда хосусыйлаштырырга планлаштырылган башка муниципаль милекнең исемлеге бар. Фараз планында (Программада) хосусыйлаштыру планлаштырыла торган муниципаль милекнең кыскача характеристикасы күрсәтелә һәм хосусыйлаштыру сроклары билгеләнә.

Муниципаль унитар предприятиеләрне үзгәртеп кору нәтиҗәсендә төзелгән акционерлык җәмгыятьләре акцияләрен устав капиталларына өлеш буларак муниципаль милекне

хосусыйлаштыруның фараз планына (программасына) үзгәрешләр кертмичә генә муниципаль милеккә кертү гамәлгә ашырыла.

4.3. Хосусыйлаштыруның фараз планында (программасында) билгеләнгән нигезләмәләр барлык җирле үзидарә органнары, унитар предприятиеләр җитәкчеләре тарафыннан үтәлергә тиеш.

4.4. Фараз планына (программасына) үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелергә мөмкин.

## 5. Муниципаль милекне хосусыйлаштыру ысуллары

5.1. Муниципаль милекне хосусыйлаштыруның түбәндәге ысуллары кулланыла:

1) унитар предприятиене акционерлык җәмгыятенә үзгәртү;

1.1) унитар предприятиене җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять итеп үзгәртү;

2) муниципаль милекне аукционда сату;

3) махсуслаштырылган аукционда акционерлык җәмгыятьләре акцияләрен сату;

4) конкурста муниципаль милекне сату;

5) халык алдында тәкъдим кертү юлы белән муниципаль милекне сату;

6) муниципаль милекне бәясен игълан итмичә сату;

7) акционерлык җәмгыятьләренең устав капиталларына өлеш буларак муниципаль мөлкәт кертү;

8) ышанычлы идарә итү нәтиҗәләре буенча акционерлык җәмгыятьләре акцияләрен сату.

Муниципаль милекне хосусыйлаштыру “Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында”гы 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә генә күрсәтелгән ысуллар белән гамәлгә ашырыла.

5.2. Муниципаль милекне сату буенча аукционнар һәм конкурслар оештыру һәм үткәрү буенча даими эшләп килүче комиссия катнашында үткәрелә, аның составы Җирлек башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан раслана.

5.3. “Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында”гы 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә, унитар предприятиеләрнең мөлкәт комплексларын хосусыйлаштыру - хуҗалык җәмгыятьләренә үзгәртү юлы белән башкарыла.

Унитар оешмаларның мөлкәт комплексларын хосусыйлаштыру түбәндәге җир кишәрлекләрен тартып алу(отчуждение) белән бер үк вакытта башкарыла:

- даими (срогы чикләнмәгән) файдалану, яки аренда хокукында унитар предприятиедә торучылар;

- хосусыйлаштырыла торган унитар предприятиенең милек комплексы составына керүче һәм әлеге объектларны файдалану өчен кирәкле булган объектларны, әлеге Нигезләмәнең 8.4 пунктында күрсәтелгән күчемсез милек объектлары белән тәэмин ителүчеләр.

5.4. Төзелеше төгәлләнмәгән һәм мөстәкыйль күчемсез милек объектлары дип танылган биналарны, корылмаларны һәм корылмаларны хосусыйлаштыру, әгәр федераль законда башкача каралмаган булса, мондый мөлкәт, җир кишәрлекләрен сатып алучы затны тартып алу(отчуждение) белән бер үк вакытта гамәлгә ашырыла.

5.5. Күчемсез милек объектлары биләгән һәм алардан файдалану өчен кирәкле җир кишәрлекләрен керткәндә, акционерлык җәмгыятьләренең устав капиталларына өлеш сыйфатында әлеге Нигезләмәнең 10 бүлегендә билгеләнгән чикләүләр кулланылмый.

## 6. Муниципаль милекне хосусыйлаштыру шартлары турында карар

6.1. Муниципаль милекне хосусыйлаштыру шартлары турындагы карар муниципаль милекне хосусыйлаштыруның фаразланган планы (программасы) нигезендә, җирлек башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан кабул ителә.

6.2. Муниципаль милекне хосусыйлаштыру шартлары турындагы карар авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән рәсмиләштерелә һәм түбәндәге мәгълүматларны үз эченә ала:

- мөлкәт атамасы һәм аны индивидуальләштерергә мөмкинлек бирә торган башка төрле мәгълүматлар (мөлкәт характеристикасы);

- милекне хосусыйлаштыру ысулы;
- муниципаль милекне хосусыйлаштырырга тиешле башлангыч бәя;
- түләүне кичектереп тору вакыты (вакыт бирелгән очракта);
- мөлкәтне хосусыйлаштыру өчен кирәкле башка мәгълүматлар.

Унитар предприятиенең милек комплексын хосусыйлаштырган очракта, муниципаль милекне хосусыйлаштыру шартлары турындагы карар белән бергә раслана:

- “Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында”гы 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясы нигезендә билгеләнгән унитар предприятиенең милек комплексын хосусыйлаштырырга тиешле составы;
- унитар предприятиенең мөлкәт комплексы составында хосусыйлаштырылырга тиеш булмаган объектлар исемлеге (шул исәптән аерым хокуклар);
- унитар предприятиене үзгәртеп кору юлы белән барлыкка килгән устав капиталы күләме акционерлык җәмгыяте, яки җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең устав капиталы күләме;
- акционерлык җәмгыяте акцияләренең саны, категорияләре һәм номиналь бәясе, яки җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьтә катнашучы өлешенең номиналь бәясе - Җирлек.

Унитар предприятиенең милек комплексы составында хосусыйлаштырылырга тиеш булмаган объектлар (шул исәптән махсус хокуклары булган), орган тарафыннан Чистай муниципаль районы казнасына алына.

Унитар предприятиенең милек комплексы составында хосусыйлаштырылырга тиешле объектлар (шул исәптән аерым хокуклар да) җирлек башкарма комитеты тарафыннан Җирлек казнасына алына.

6.3. Муниципаль милекне хосусыйлаштыруның Фараз планын (программасын) раслаганнан соң һәм төзелгән хуҗалык җәмгыятен дәүләт теркәве көненә кадәр аның милекчесенең язма рөхсәтеннән башка унитар предприятиягә хокукы юк:

- әлеге унитар предприятие хезмәткәрләренең санын киметергә;
- аның соңгы баланс хисабын раслау датасына карата, яки Федераль закон белән билгеләнгән минималь хезмәт хакыннан илле меңнән артып киткән килешүләр (берничә бәйле килешү) ясау, бәясе күрсәтелгән унитар предприятие активларының баланс бәясенең 5 процентыннан арткан килешүләр, аның бәясе соңгы баланс хисабын раслау датасына, яки Федераль закон белән билгеләнгән минималь хезмәт хакыннан илле меңнән артык булган мөлкәтне турыдан-туры, яки турыдан-туры тартып алу мөмкинлеге белән алыш-бирешләр (берничә үзара бәйле килешү);
- кредит алу;
- кыйммәтле кәгазьләр чыгару;
- хуҗалык ширкәтләрен яки җәмгыятьләрне гамәлгә куючы булу, шулай ук хуҗалык ширкәтләренең, яки ширкәтләренең устав (җыелма) капиталында акцияләрне (өлешләрне) сатып алырга һәм читләштерергә.

6.4. Муниципаль милекне сату, гамәлдәге законнарда каралган мәҗбүри шартларны күрсәтеп, сату-алу килешүе белән рәсмиләштерелә.

## 7. Муниципаль милекне хосусыйлаштыру буенча мәгълүмат җиткерү.

7.1. Муниципаль милекне хосусыйлаштыруны мәгълүмат белән тәэмин итү дигәндә, чикләнмәгән даирәдәге затларның хосусыйлаштыру турындагы мәгълүматка ирекле үтеп керү мөмкинлеген булдыруга юнәлтелгән чаралар һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) “Интернет” челтәрендәге рәсми сайтка урнаштыруны, муниципаль милекне хосусыйлаштыру шартлары турындагы карарларны, муниципаль милекне сату турында мәгълүмати хәбәрләрне һәм аны сату нәтиҗәләре турында мәгълүматны үз эченә ала.

7.2. Муниципаль милекне хосусыйлаштыру, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән торгларны үткәрү турындагы мәгълүматны урнаштыру өчен “Интернет” челтәрендәге Россия Федерациясенең рәсми сайты www.torgi.gov.ru хезмәт күрсәтә.

7.3. Муниципаль милекне сату, аны сату нәтиҗәләре турында “Интернет” челтәрендә муниципаль мөлкәт сатучының сайтында да урнаштырыла.

Муниципаль милекне сату турында мәгълүмати хәбәр “Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында”гы 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законда башкасы каралмаган булса, “Интернет” челтәрендәге рәсми сайтта, күрсәтелгән мөлкәтне сату

гамәлгә ашырылган көнгә кадәр утыз көннән дә ким булмаган вакыт эчендә урнаштырылырга тиеш.

Муниципаль милекне хосусыйлаштыру шартлары турындагы карар “Интернет” челтәрендәге рәсми сайтта әлеге карар кабул ителгән көннән соң ун көн эчендә урнаштырыла.

7.4. Муниципаль милекне сату турында мәгълүмати хәбәрдә, “Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында”гы 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очраклардан тыш, түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

1) мондый мөлкәтне хосусыйлаштыру шартлары турында Карар кабул иткән җирле үзидарә органы исеме, күрсәтелгән карар реквизитлары;

2) мондый мөлкәтнең атамасы һәм аны индивидуальләштерергә мөмкинлек бирә торган башка төрләр (мөлкәт характеристикасы);

3) мондый милекне хосусыйлаштыру ысулы;

4) мондый милекне сату буенча башлангыч бәясе;

5) мондый мөлкәтнең бәясе турында тәкъдимнәр бирү формасы;

6) түләү шартлары һәм сроклары, кирәкле реквизитлар;

7) алдан бирелгән акчаның(задаток) күләме, аны кертү вакыты һәм тәртибе, кирәкле реквизитлар;

8) гаризалар бирү тәртибе, урыны, вакыты һәм тәмамлану вакыты, тәкъдимнәр;

9) сатуларда катнашучылар тарафыннан тапшырыла торган документларның тулы исемлеге һәм аларны рәсмиләштерүгә таләпләр;

10) мондый милекне сату-алу килешүе төзү вакыты;

11) сатып алучыларны башка мәгълүмат, мондый милекне сату-алу килешүе шартлары белән таныштыру тәртибе;

12) аерым категория физик затларның һәм юридик затларның мондый милекне хосусыйлаштыруда катнашуын чикләү;

13) җиңүчеләрне (аукцион, махсус аукцион, конкурс үткәргәндә) билгеләү тәртибе, яки дәүләт, яки муниципаль мөлкәт сатып алу хокукына ия булган затларны (аны халык алдында тәкъдим кертү юлы белән сатканда, бәяне игълан итмичә генә) билгеләү тәртибе;

14) муниципаль милекне сатуга йомгак ясау урыны һәм вакыты;

15) сатылыр алдыннан ел дәвамында игълан ителгән мондый милекне сату һәм мондый милекне сату нәтиҗәләре турында мәгълүматлар;

7.5. Муниципаль милектә булган акционерлык җәмгыяте акцияләрен, яки җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең устав капиталындагы өлешен сатканда, шулай ук “Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында”гы 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 пунктында билгеләнгән белешмәләр күрсәтелә.

7.6. Җирлек башкарма комитеты карары буенча, мәгълүмат хәбәрендә шулай ук өстәмә мәгълүмат күрсәтелә ала.

7.7. Гаризалар кабул ителгән көннән башлап, муниципаль милекне сатып алырга теләгән зат хосусыйлаштырылырга тиешле милек турындагы мәгълүмат белән танышырга хокуклы.

Гаризалар бирү урыннарында һәм “Интернет” челтәрендәге муниципаль милекне сатучы сайтында муниципаль милекне хосусыйлаштырырга тиешле сатулар турында ачык мәгълүмат, муниципаль милекне сатып алучылар тарафыннан тәкъдим ителә торган типик документлар үрнәкләре, сатуларны үткәрү кагыйдәләре урнаштырылган булырга тиеш.

7.8. Муниципаль милекне хосусыйлаштыру нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат “Интернет” челтәрендәге рәсми сайтта күрсәтелгән килешүләр төзелгән көннән соң, ун көн эчендә урнаштырылырга тиеш.

## 8. Халык алдында тәкъдим итү юлы белән муниципаль милекне сату.

8.1. Муниципаль милекне халык алдында тәкъдим итү юлы белән сату (алга таба - халык алдында тәкъдим итү юлы белән сату) әлеге мөлкәтне сату буенча аукцион үткәрелмәгән дип табылган очракта гына тормышка ашырыла. Шул ук вакытта ачык тәкъдим итү юлы белән сату турында мәгълүмати хәбәр “Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында”гы 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясында билгеләнгән тәртиптә, аукцион узмаган дип танылган көннән соң, өч айдан да соңга калмыйча урнаштырыла.

8.2. “Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында”гы 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясында каралган белешмәләр белән беррәттән күмәк тәкъдим ярдәмендә сату турында мәгълүмати хәбәрдә түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

1) сатуны үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;

2) “Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында”гы 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законда (“аукцион адымы”) каралган очракта, беренчел тәкъдимнең бәясен киметү зурлыгы (“кимү адымы”), яки бәя арту күләме;

3) муниципаль милек сатылырга мөмкин булган тәкъдимнең минималь бәясе (чигенү бәясе).

8.3. Аукцион үткәрелмәде дип танылган очракта, беренчел тәкъдимнең бәясе, 8.1. сату турында мәгълүмат хәбәрендә күрсәтелгән башлангыч бәядән дә ким булмаска тиеш, ә мондый аукционның башлангыч бәясе 50 процент тәшкил итә.

8.4. Гаризалар кабул итү дәвамлылыгы кимендә егерме биш көн. Бер кеше бары тик бер генә гариза бирергә хокуклы. Претендентларны ачык тәкъдим итү юлы белән сатуда катнашучылар дип тану гаризалар кабул итү вакыты тәмамланганнан соң, биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла. Халык алдында тәкъдим итү юлы белән сату, претендентлар танылган көннән соң, өченче эш көненнән дә соңга калмыйча, халык алдында тәкъдим итү юлы белән үткәрелә.

8.5. Сатуда катнашу өчен дәгъва кылучы муниципаль милекне сату турындагы мәгълүмати хәбәрдә күрсәтелгән башлангыч бәянең 20 проценты күләмендә задаток кертә.

Мәгълүмати хәбәрдә күрсәтелгән счетка задаток килүен раслаучы документ булып, әлеге счеттан өземтә тора.

8.6. Халык алдында тәкъдим кертү юлы белән сату, мондый сатуны үткәрүнең бер процедурасы дәвамында муниципаль милекне сатып алу турындагы тәкъдимнәрне бирүнең ачык формасын кулланып башкарыла.

8.7. Ачык тәкъдим юлы белән сатканда, “кимү адымы” на беренчел тәкъдимнең бәясен төшерүгә кадәр эзлекле рәвештә киметү гамәлгә ашырыла.

8.8. Муниципаль мөлкәтне сатып алу хокукы сатуда катнашучыга ачык тәкъдим юлы белән бирелә, ул сатуда башка катнашучыларның тәкъдимнәре булмаганда, беренчел тәкъдимнең бәясен, яки тиешле “кимү адымы”нда барлыкка килгән тәкъдимнең бәясен раслый.

8.9. Сатуда катнашучы берничә кеше ачык тәкъдим ярдәмендә беренче тәкъдимнең бәясен, яки “кимү адымнары”нда барлыкка килгән тәкъдимнең бәясен расласа, сатуда катнашучылар белән ачык тәкъдим ярдәмендә “Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында”гы 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә аукцион үткәрү кагыйдәләре буенча аукцион үткәрелә. Мондый аукционда муниципаль мөлкәтнең башлангыч бәясе булып беренчел тәкъдим бәясе, яки әлеге “кимү адымында” барлыкка килгән тәкъдим бәясе тора.

8.10. Әгәр мондый аукционда катнашучылар муниципаль мөлкәтнең башлангыч бәясеннән артып китә торган бәя турында тәкъдимнәр белдермәсә, аны сатып алу хокукына аукционда катнашучы ия була, чөнки ул беренче булып муниципаль мөлкәтнең башлангыч бәясен раслый.

8.11.Халык алдында тәкъдим итү ярдәме белән сатуда бер генә катнашучы булса,ул оештырылмаган дип таныла.

8.12. Претендентка түбәндәге нигезләр буенча халык алдында тәкъдим итү юлы белән сатуда катнашырга рөхсәт ителми:

1) тәкъдим ителгән документлар претендентның закон нигезендә сатып алучы булу хокукын расламый;

2) муниципаль милекне сату турында мәгълүмат хәбәрендә күрсәтелгән исемлек буенча барлык документлар да тапшырылмаган, яисә әлеге документларны рәсмиләштерү Россия Федерациясе законнарына туры килми;

3) халык алдында тәкъдим итү юлы белән сатуда катнашуга гариза бирүче, мондый гамәлләрне башкаруга дәгъва кыла алмый;

4) мәгълүмати хәбәрдә күрсәтелгән счетларга билгеләнгән вакытка задатокның килүе расланмаган.

8.13. Дәгъвачыга сатуда катнашудан баш тарту өчен 8.12 күрсәтелгән нигезләр исемлеге ачыктан-ачык дәлил булып тора.

8.14. Претендент әлеге гаризаны сатуда катнашучы дип танылган вакытка кадәр халык алдында тәкъдим итү юлы белән сатуда катнашуга чакыртып алу хокукына ия.

8.15. Сатуда катнашучыны ачык тәкъдим юлы белән тану турындагы хәбәрнамә җиңүчегә сатуга йомгак ясалган көнне ачык тәкъдим ярдәмендә җибәрелә.

8.16. Җиңүче сатудан качкан, яки сатудан баш тарткан очракта, мөлкәт сату-алу килешүе төзүдән күмәк тәкъдим итү юлы белән күрсәтелгән Шартнамәне төзү хокукын югалта һәм задаток аңа кире кайтарылмый.

8.17. Задаток суммалары, мондый сатуда җиңүчедән тыш, сатуда катнашучыларга, йомгак ясаган көннән биш көн эчендә кире кайтарыла.

8.18. Ачык тәкъдим итү юлы белән сату үткәрелгәннән соң, биш эш көненнән дә соңга калмыйча җиңүче белән сату-алу килешүләре төзелә.

8.19. Муниципаль милекне тапшыру һәм аңа милек хокукын рәсмиләштерү Россия Федерациясе законнары нигезендә, мөлкәткә тулысынча түләгәннән соң, утыз көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

8.20. Муниципаль милекне халык алдында тәкъдим итү юлы белән сату тәртибе РФ Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

## 9. Муниципаль милекне бәяне игълан итмичә сату

9.1. Әгәр милекне халык алдында тәкъдим итү юлы белән сату оештырылмаган булса, муниципаль милекне бәяне игълан итмичә үткәрелә.

Муниципаль милекне бәяләрне игълан итмичә генә сатканда аның башлангыч бәясе билгеләнми.

9.2. Муниципаль милекне бәяне игълан итмичә генә сату турында мәгълүмати хәбәр “Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында”гы 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясында каралган таләпләргә туры килергә тиеш.

Дәгъва белдерүчеләр үзләренең тәкъдимнәрен мәгълүмати хәбәрдә күрсәтелгән адреска җибәрәләр.

Муниципаль милекне сатып алу турындагы тәкъдимнәр сату барышында дәгъва кылучылар тарафыннан ачыктан-ачык белдерелә.

9.3. Дәгъва кылучы, муниципаль милек бәясе турындагы тәкъдимнән тыш, “Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында”гы 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясында күрсәтелгән документларны тапшырырга тиеш.

9.4. Берничә дәгъвачыдан тәкъдимнәр кергән очракта, сатып алучы дип муниципаль милек өчен иң зур бәяне тәкъдим иткән зат танылa.

9.5. Муниципаль милек бәясе турында берничә бертөрле тәкъдим кергән очракта, сатып алучы дип иң беренче гариза биргән зат дип таныла.

## 10. Акционерлык җәмгыятьләренең устав капиталларына өлеш буларак муниципаль мөлкәт кертү

10.1. Муниципаль милек, шулай ук аерым хокуклар җирлек башкарма комитеты тәкъдиме нигезендә, җирлек Советы карары буенча акционерлык җәмгыятьләренең устав капиталларына өлеш сыйфатында кертелергә мөмкин. Шул ук вакытта җирлек милкендә булган һәм җирлек тарафыннан сатып алына торган акционерлык җәмгыяте акцияләренең гадәти акцияләренең гомуми саны 25 проценттан һәм өстәмә тагын бер акциядән ким булырга тиеш түгел.

10.2. Акционерлык җәмгыятьләренең устав капиталларына муниципаль мөлкәт, шулай ук аерым хокуклар кертү гамәлгә ашырылырга мөмкин:

- акционерлык җәмгыятьләрен оештыру буенча;

- акционерлык җәмгыятьләренең устав капиталларын арттырганда, урнаштырыла торган өстәмә акцияләрне түләү тәртибендә.

10.3. Муниципаль мөлкәт, шулай ук урнаштырыла торган өстәмә акцияләрне түләү сыйфатында аерым хокуклар кертү түбәндәге шартларны үтәгәндә гамәлгә ашырылырга мөмкин:

акционерлык җәмгыяте, акционерлык җәмгыятьләре турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә, өстәмә акцияләр урнаштыру юлы белән, шул исәптән муниципаль мөлкәт тарафыннан да, устав капиталын арттыру турында Карар кабул итте (мондый мөлкәт төрен күрсәтеп), шулай ук Татарстан Республикасы Җирлек берәмлегенә карый торган аерым хокукларга таянып (тиешле аерым хокукларның күләмен, чикләрен һәм ысулын күрсәтеп);

түләүләргә муниципаль милек һәм (яки) аерым хокуклар кертелә торган өстәмә акцияләр гадәти акцияләр булып исәпләнә;

өстәмә акцияләр өчен кертелә торган муниципаль милекне бәяләү эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары нигезендә башкарыла.

10.4. Муниципаль милек, шулай ук устав капиталына өлеш буларак аерым хокуклар керткәндә Җирлек милкенә сатып алына торган акцияләр саны, акционерлык җәмгыятенең гадәти акцияләренең гомуми санында әлеге акцияләрнең өлеше һәм акционерлык җәмгыятенең устав капиталына өлеш буларак кертелә торган муниципаль мөлкәт хакы (күрсәтелгән акцияләрне сатып алу бәясе) "Акционерлык җәмгыятьләре турында"гы Федераль закон һәм бәяләү эшчәнлеге турында Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә.

## 11. Социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнештәге объектларны хосусыйлаштыру

11.1. Социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнештәге объектларны хосусыйлаштыру үзенчәлекләре "Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында"гы 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон белән җайга салына.

11.2. Социаль-мәдәни билгеләнештәге объектлар (сәламәтлек саклау, мәдәният һәм спорт) һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнештәге объектлар, билгеләнеше буенча кулланылудан тыш, муниципаль унитар предприятиенең милек комплексы составында хосусыйлаштырылырга мөмкин:

- халыкны социаль яклау органнары, шул исәптән өлкәннәр өчен, госпитальләр һәм инвалидлар һәм картлар өчен шифаханәләр өчен йортлар, социаль яклау органнары;

- авыл җирлегендә яшәүчеләргә хезмәт күрсәтү өчен билгеләнгән сәламәтлек саклау, мәдәният объектлары;

- балалар өчен социаль инфраструктура объектлары;

- торак фонды һәм аның инфраструктурасы объектлары;

- Җирлектә яшәүчеләргә хезмәт күрсәтү өчен билгеләнгән транспорт һәм энергетика объектлары.

11.3. Әлеге пунктта күрсәтелгән объектлар, балалар өчен социаль инфраструктура объектларыннан тыш, билгеләнүне үзгәртү тиешле җирле үзидарә органнары белән килештереп гамәлгә ашырыла. Балалар өчен социаль инфраструктура объектларын билгеләүне үзгәртү 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында"гы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

## .12. Җир кишәрлекләрен тартып алу үзенчәлекләре

12.1. Җирлек муниципаль берәмлеге милкендә булган унитар оешмаларның милек комплекслары, хосусыйлаштыру һәм хосусыйлаштыру объектлары өчен җир кишәрлекләрен тартып алу законнарда билгеләнгән тәртиптә, "Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында"гы 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 28 маддәсе нигезендә башкарыла.

12.2. Җир кишәрлеген сатып алу бәясе гамәлдәге законнар нигезендә билгеләнә.

12.3. Түбәндәге очракларда, җир составындагы җир кишәрлекләре тартып алырга рөхсәт ителми:

урман фонды һәм су фонды, аеруча саклана торган табигый территорияләр һәм объектлар;

куркыныч матдәләр белән зарарланган һәм биологик зарарлануга дучар ителгән;

гомуми файдаланудагы (мәйданнар, урамнар, юллар, автомобиль юллары, яр буйлары, парклар, урман парклары, скверлар, бакчалар, бульварлар, су объектлары, пляжлар һәм башка объектлар);

Россия Федерациясе законнары нигезендә тартып алырга тиеш булмаган.

12.4. Муниципаль ихтыяҗлар өчен резервланган җир кишәрлекләре чикләрендә муниципаль милектәге җир кишәрлекләре читкә чыгарылмаска тиеш.

## 13. Муниципаль милекне сату-алу килешүләрен рәсмиләштерү

13.1. Муниципаль милекне сату-алу килешмә ярдәмендә рәсмиләштерелә.

13.2. Муниципаль милекне сату-алу шартнамәсенең мәҗбүри шартлары булып тора:

чикләнгән җәмгыятьнең устав капиталында өлеше күләме; сатып алучы милкенә муниципаль милекне тапшыру тәртибе һәм вакыты; сатып алынган мөлкәт өчен түләү рәвеше һәм сроклары; күрсәтелгән мөлкәтнең сатып алучы тарафыннан сатып алынган шартлары; акционерлык җәмгыятенең составы һәм бәясе; акционерлык җәмгыятенең акцияләр саны, аларның категориясе яисә җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең устав капиталында өлеше күләме; сатып алучы милкенә муниципаль милекне тапшыру тәртибе һәм вакыты; сатып алучы тарафыннан күрсәтелгән мөлкәтнең түләү рәвеше һәм сроклары;

күрсәтелгән мөлкәткә карата сатып алучы тарафыннан вәкаләтләрне күрсәтелгән милеккә күчкәнче гамәлгә ашыру тәртибе;

сатыла торган бина, төзелмә, корылма, яки җир кишәрлеге (шул исәптән күмәк сервитут) карата күрсәтелгән объектларга хокук күчкәндә, саклана торган белешмәләр;

килешү төзүче ике як тарафыннан мондый шартнамәнең үзара килешү буенча билгеләнгән башка шартлар.

Сатып алынучы йөкләмәләре, сатып алына торган муниципаль мөлкәткә карата, эшләрне башкару, акча түләү белән бәйле гамәлләр кылудан тыш, аларны үтәү срокларына, шулай ук Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә торган бәя күләменә ия булырга тиеш.

13.3. Сатып алына торган муниципаль мөлкәткә милек хокукы сатып алучыга, “Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында”гы 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, тулысынча түләгәннән соң, билгеләнгән тәртиптә күчә.

13.4. Күчемсез милек хокукы милек хокукы сатып алучыга хосусыйлаштырыла торган милеккә дәүләт теркәве алган көннән күчә. Күчемсез милекне сату-алу килешүе, шулай ук милекне кабул итү-тапшыру акты мондый мөлкәтне дәүләт теркәвенә алу өчен нигез булып тора. Регистратор хезмәтләре өчен түләү чыгымнары сатып алучыга йөкләнә.

13.5. Муниципаль милекне сату тәртибен бозу, сатуларда катнашучы дип танылудан хокуксыз баш тарту, милекне сату нәтиҗәләре буенча төзелгән алыш-бирешнең төзелмәвенә китерә.

## 14. Муниципаль милеккә түләү тәртибе

14.1. Сатып алучы тарафыннан сатып алына торган муниципаль мөлкәт өчен түләү муниципаль мөлкәтне сату-алу шартнамәсе шартлары нигезендә килешү төзелгән көннән алып 10 (ун) эш көне эчендә башкарыла.

14.2. Кичектереп түләү бирү турындагы карар муниципаль милекне бәяне игълан итмичә генә саткан очракта орган тарафыннан кабул ителергә мөмкин. Вакытны кичектереп түләү бер елдан да артык була алмый.

Кичектереп түләү бирү турындагы карарда аны бирү сроклары һәм түләүләрне кертү тәртибе күрсәтелә. Кичектереп түләү бирү вакыты һәм түләүләрне кертү тәртибе муниципаль милекне хосусыйлаштыру турындагы мәгълүмати хәбәрдә булырга тиеш.

14.3. Түләү срогы бирелә торган акча суммасына, “Интернет» челтәре сайтларында урнаштыру датасына гамәлдә булган Россия Федерациясе Үзәк банкы рефинанслау ставкасының өчтән бер өлешеннән чыгып, процентлар исәпләнелә. Исәпләнгән процентлар Россия Федерациясе Бюджет кодексы белән билгеләнгән тәртиптә күчерелә.

Сатып алучы сатып алынган муниципаль милекне вакытыннан алда түләргә хокуклы.

14.4. Сатып алучыга сатып алынган мөлкәтне кичектереп түләү шарты белән, һәм тулысынча түләү мизгеленә кадәр, әлеге мөлкәт сатып алучы тарафыннан сатып алынган муниципаль мөлкәтне түләү буенча бурычларын үтәүне тәэмин итү өчен залогта булган дип таныла.

14.5. Сатып алучылар сатып ала торган муниципаль милекне вакытында түләмәгән өчен, килешү шартлары нигезендә акчалата йөкләмәләрне үтәү датасына гамәлдә булган Россия Федерациясе Үзәк банкы рефинанславының өч йөз процентлы ставкасының һәр көне өчен пенялар түләнә.

Сатып алучы тарафыннан салынган мөлкәткә түләүләр кертү вакыты һәм тәртибе бозылган очракта, суд тәртибендә түләттерүне таләп итә.

Сатып алучыдан муниципаль милекне сату-алу шартнамәсен үтәмәгән зыяннар да түләттерелергә мөмкин.

14.6. Дәүләт, яисә муниципаль мөлкәтне сату-алуның гамәлдә булмаган алыш-бирешләре буенча акчаларны кире кайтару Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, мондый мөлкәтне федераль милеккә, Россия Федерациясе субъекты милкенә яисә муниципаль милеккә тапшырганнан соң, үз көченә кергән суд карары нигезендә, федераль бюджет, Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары һәм җирле бюджетлар акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

## 15. Муниципаль милекне электрон формада сату

15.1. Муниципаль милекне электрон формада сату "Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында»гы 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 18-20, 23, 24 статьяларында билгеләнгән ысуллар белән башкарыла. Әлеге статьяларның нигезләмәләре муниципаль мөлкәтне сатуны уздыру өлешендә «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында»гы 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 32.1 статьясында билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып кулланыла.

15.2. Муниципаль милекне сатуны электрон формада үткәрү турындагы мәгълүматлар мондый милекне хосусыйлаштыру шартлары турындагы карарда булырга тиеш.

15.3. Электрон формада муниципаль милекне сату (алга таба - электрон формада сату) электрон мәйданчыкта башкарыла.

15.4. Электрон формада сату үткәргәндә электрон мәйданчык операторы түбәндәгеләрне тәэмин итә:

1) сату үткәрү турында электрон формада ирекле һәм бушлай мәгълүмат алу;

2) претендентлар тарафыннан гаризалар һәм аларга кушымта бирү мөмкинлеге;

3) дәгъва кылучылар тарафыннан тапшырыла торган гаризаларны һәм башка документларны, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә сертификацияләнгән мәгълүматны саклау чараларын кулланып, электрон формада саклау һәм эшкәртү;

4) претендентлар тарафыннан тапшырыла торган мәгълүматны (гаризаларны һәм башка документларны) яклау, шул исәптән күрсәтелгән мәгълүматның сакланышы, аны юк итүне кисәтү, санкцияләнмәгән үзгәрешләр һәм күчермәләр;

5) мәгълүмат һәм документларны булдыру, эшкәртү, саклау һәм электрон формада тапшыру, шул исәптән сату нәтиҗәләре турында электрон формада җиткерү;

6) электрон мәйданчыкның өзлексез эшләве һәм аның кулланучылары, шул исәптән сатуда катнашучылар, мондый сату үткәрү вакытында электрон формага керү мөмкинлеге бар.

15.5. "Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында"гы 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законда каралмаган очраклардан тыш, электрон формада сатуда катнашучылардан өстәмә түләү алу тыела.

15.6. Сатуны үткәрү турында электрон формада мәгълүмат урнаштыру "Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында"гы 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

«Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында»гы 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясында каралган белешмәләр белән беррәттән, «Интернет» челтәрендә сатуны үткәрү турында электрон мәгълүмат хәбәрендә электрон формада сатылачак электрон мәйданчык, электрон мәйданчыкта теркәү тәртибе, сату үткәрү кагыйдәләре, аны үткәрү датасы һәм вакыты күрсәтелә.

15.7. Электрон формада сатуда катнашу өчен дәгъвачылар электрон мәйданчыкта сату турындагы мәгълүмати хәбәрдә күрсәтелгән тәртиптә теркәлергә тиеш.

Сатуда катнашучыларны электрон формада тану, яки мондый сатуда катнашудан баш тарту турында карар муниципаль милек сатучы тарафыннан кабул ителә.

15.8. Муниципаль милек бәясе турындагы тәкъдимнәрне тәкъдим итү сатуда теркәлгән катнашучы тарафыннан электрон формада бер процедураны үткәрү барышында гамәлгә ашырыла.

15.9. Әлеге процедура үткәрелә торган электрон мәйданчыкта сату процедурасы башлану датасыннан һәм вакытыннан башка күрсәтелергә тиеш:

1) муниципаль мөлкәт атамасы һәм аны шәхсиләштерергә мөмкинлек бирә торган башка төр белешмәләр (лот спецификациясе);

2) аукционда сатылган очракта-башлангыч бәя, башлангыч бәяне арттыру күләме (“аукцион адымы”);

3) башлангыч тәкъдимнең бәясе, “кимү адымы” бәясе, тәкъдимнең минималь бәясе, әлеге Федераль законда каралган очракта (“аукцион адымы”) бәя арту күләме - ачык тәкъдим ярдәмендә сатылган очракта, муниципаль милек сатылырга мөмкин булган тәкъдимнең минималь бәясе һәм бәя арту күләме (“аукцион адымы”);

4) муниципаль мөлкәтнең бәясе һәм аның реаль вакыт режимында керү вакыты турында соңгы тәкъдим.

15.10. Дәүләт, яки муниципаль милекне бәясен күрсәтмичә генә сатканда, аның башлангыч хакы турында да әйтелми.

15.11. Электрон формада сату процедурасы тәмамланганнан соң, бер сәгать эчендә сатыла торган электрон мәйданчыкта электрон формада урнаштырыла:

1) мөлкәт атамасы һәм аны шәхсиләштерергә мөмкинлек бирә торган башка төр белешмәләр (лот спецификациясе);

2) хосусыйлаштыру килешүе бәясе;

3) сатуларда җиңүче физик затның исеме, яки юридик затның исеме.

15.12. Сату процедурасының нәтиҗәләре электрон формада беркетмә белән рәсмиләштерелә.

15.13. Электрон формада сатуны оештыру һәм үткәрү тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.